**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Димитарлау авылы торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 15 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Димитарлау авылында граждannар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1)2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Димитарлау авыл җирлеге территориясендә I нче группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкән кешеләр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2)Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) гомуми автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге файдалану:

-Димитарлау торак пунктында Беларус-82,1 тракторын тоту (водитель хезмәтләренә түләү, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

-Димитарлау авылында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр һәм чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) ;

2) урам яктырту җайланмасы:

-Димитарлау торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

3) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:

- Димитарлау торак пунктынын М.Җәлил урамында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (килешү буенча материаллар сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү);

4)ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Димитарлау торак пунктындагы зират территориясенә койма өчен материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән сон 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р.Нуртдинов